СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 Баулы шәһәре № 31

«Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль
районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектын (1нче кушымта) хупларга һәм фикер алышуга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Карар проектын 1нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

- гражданнарның «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2нче кушымта);

- «Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

4. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектын (1нче кушымта);

- гражданнарның «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль

берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен (2нче кушымта);

- «Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемне түбәндәге составта төзергә:

1. Попов Сергей Александрович - эшче төркем рәисе.

2. Сафина Эльвира Әнис кызы - эшче төркем әгъзасы.

3. Багижева Светлана Николаевна - эшче төркем әгъзасы.

6. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2021 елның 15 мартында 15.00 сәгатьтә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы 20 нче йорт.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы депутатларының һәм гражданнарның Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы муниципаль районы Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе                                        Р.Х. Гатиятуллин